Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрожжановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1021606556850 ИНН 1617000612

==================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

02 июнь 2020 ел № 57/3

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 26.04.2012 ел, № 14/3 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә» (15.10.2018 ел, № 37/2 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

**«**2.1. Ачык тыңлаулар халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге башлыгы, авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә.**»;**

**4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«4.1. Халык яки авыл җирлеге Советы инициативасы белән үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы, ә авыл җирлеге башлыгы яки авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән контракт нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы авыл җирлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып

чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга..

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов